

*Габдулла Тукай*

*(1886 – 1913)*

***“Сатмас егет илен алтын көмешләргә,***

***Әгәр югалтмаса вөҗданын.***

***Алтынны ул чүпкә санар,***

***Иң кыйммәтле күрер Ватанын.”***

*Бөек шагыйрь Арча ягының Кушлавыч*

*авылында 1886 елның 26 апрелендә (иске стиль буенча 14 апрельдә) Мөхәммәтгариф мулла гаиләсендә дөньяга килә. Малай туып дүрт ай ярым үткәч, Мөхәммәтгариф хәзрәт үлеп китә. Тол калган Мәмдүдәне (Габдулланың әнисен) Сасна Пүчинкәсе авылы мулласына кияүгә бирәләр. Бәләкәй Габдулланы авылның Шәрифә исемле фәкыйрь бер карчыгына вакытлыча асрамага калдыралар. Бераз соңрак аны үз әнисе яңа гаиләсенә алдыра. Ләкин озакламый үлеп китә һәм үги әтисе аны Өчилегә бабасына озата.*



*Бәләкәй Габдулла монда ятимлекне генә түгел,*

*ачлыкны да татый. Ә бервакыт баланы, Казанга*

*баручы бер ямщиккә утыртып, ерак, билгесез сәфәргә озаталар. Теге ямщик исә Печән базарына килгәч: «Асрарга бала бирәм, кем ала?» — дип кычкырып йөри. Халык арасыннан бер кеше чыгып малайны үзләренә алып кайта. Яңа бистә һөнәрчесе Мөхәммәтвәли абзый белән Газизә абыстай шулай итеп малайлы булалар. Соңрак аны яңадан Өчилегә озаталар. Бераздан соң малайны Кырлай исемле авылдан ир баласыз Сәгъди абзыйга уллыкка озаталар. Шулай көннәрдән бер көнне Кушлавыч авылының Бәдретдин исемле туган тиешле кешесе Тукайны эзләп таба да Уральскига алып китә.*

## *Уральск чоры*

*1895 елның кышында 18 көнле юлдан соң тугыз яшьлек Апушны Уральск шәһәрендәге татар бистәсенә сәүдәгәр Усманов Галиәскәр һәм аның хатыны Газизә йортына алып киләләр. Уральск халкы тарихта беренче мәртәбә ачыктан-ачык Беренче май демонстрациясен уздыра*



*1905–1907 елларда Тукай бик кыю публицистик*

*мәкаләләр белән чыгыш ясый. Галиәскәр вафат булганнан соң Тукай "Мотыйгия" мәдрәсәсенә күчеп килә. Мотыйгия мәдрәсәсендә монда Зөя өязеКече Кайбыч авылыннан күчеп килгән Мотыйгулла хәзрәт Төхбәтуллин шәкертләргә фәлсәфә, астрономия фәннәре буенча дәресләр бирә, Омар Хәйям, Фирдәүси һәм башка дан казанган шәрык шагыйрь-ләренең эшләре белән таныштыра. Югары белемле алдынгы карашлы, бай китапханәгә ия булган бу шәхеснең Тукайның шагыйрь булып формалашуында роле чагыштыргысыз зур. "Мотыйгыя" мәдрәсәсе каршында рус мәктәбе эшләп килгән. Алдан Тукай русча бер нәрсә дә аңламаган булса, берничә айдан соң йөгереп укый башлаган.*

*1905 елның сентябрендә «Әлгасрелҗәдид» журналының реклама җыентыгында шигырьләре басыла. Ноябрьдә «Фикер» газетасы чыга башлый. Бераздан «Әл-гасрелҗәдид» күренә. Тукай инде монысында фактик редактор. Хыялда сатирик журнал чыгару. 1906 елның июнендә анысы да («Уклар») дөнья күрә. Монда да редактор — Тукай.*

## *Казан чоры*



*1907 елның сары яфраклар белән түшәлгән Казан урамына атлы повозкага утырып Тукай килеп керә. Шушы елның көзеннән Тукайның Казан чоры — халкына, Ватанына шигъри сүзен әйтер өчен бирелгән биш ел да сигез айлык дәвере башлана. Казанда Тукай яңа дуслар таба. Болар: Фатих Әмирхан, Хөсәен Ямашев, Кәбир Бәкер һ.б.*

*1910 елның башында журналист Әхмәт Урманчиев редакторлыгында сатирик журнал «Ялт-йолт» чыга башлый. Тукай бөтен көчен шушы журналга бирә, сатирик әсәрләренең бик күбесе «Ялт-йолт»та басыла. Ул шәһәрнең иҗтимагый эшләрендә актив катнаша.*



*1913 елның башында шагыйрьнең сәламәтлеге бик нык какшый. Ләкин ул иҗат эшен туктатмый. Тукайның соңгы айларында язган әсәрләре аның чын мәгънәсендә зур патриот, гражданин һәм тарихны тирәнтен аңлаган шәхес икәнен исбат итәләр. 1913 елның 15 апрелендә (иске стиль буенча 2 апреле) бөек шагыйрь Габдулла Тукайның гомере өзелә.*



*Тукай кыска гына иҗат гомерендә 350 шигырь,
107 мәсәл һәм балалар өчен хикәяләр,
130 мәкалә һәм фельетон яза.*

## *Балалар өчен 10 әсәре*

*Габдулла Тукайның балалар өчен иҗат иткән шигырьләре шактый күп. Аларның күбесе җырга әйләнгән, сүзләрен укый башлагач, үзеннән-үзе көйли дә башлыйсың («Туган авыл», «Карлыгач»). Тукай балалар күңелен аңлап, кызыклы образлар тудырып әлеге темаларга җавап табарга, еш кына баланың үзеннән геройларның кылган гамәлләреннән сабак алырга өнди.*

1. «Шүрәле»

Балаларның гына түгел, олыларны да уйландырырга мәҗбүр итә торган әсәрләрнең берсе. Әле һаман да галимнәрне «Былтыр уңай героймы әллә юкмы?» дигән сораулар борчый.

2. «Су анасы»

Кеше әйберен урларга ярамый икәнен бик яхшы төшендерә торган икенче шигырь. Бала исеменнән сөйләү аны тагын да ныграк тоярга, аңларга ярдәм итә.

3. «Гали белән Кәҗә»

Бу юлларны, кәҗәнең нигә сакал селкетүен белмәгән кеше юктыр.

4. «Кәҗә белән Сарык хикәясе»

Юмор белән җәмгыятьтә барган проблемаларны бергә үреп биргән Тукай чын-чынлап зирәк каһарманнарына гашыйк итә.

5. «Бала белән күбәләк» Я, әйт әле күбәләк…

6. «Сабыйга»

Әлеге шигырь әйтерсең лә «Шүрәле», «Су анасы»н укыган сабыйларга багышлап язылган. Тукай курыкмаска һәм бу нәрсәләрне бары тик шагыйрь уйдырмасы, ялган буларак кына кабул итәргә чакыра.

7. «Кызыклы шәкерт»

Яшьтән үк эшкә өйрәнергә кирәк икәнлеген шагыйрь шук Акбай образында күрсәтә.

8. «Эш беткәч уйнарга ярый»

9. «Бишек җыруы»

10. «Кышкы кич"